**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 20 гыйнварындагы 48 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы**
**«Вахитов районының Бауман урамындагы җир кишәрлекләренә**
**ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы «Вахитов районының Бауман урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы «Вахитов районының Бауман урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**